**СОВЕТ АЛЕКСАНДРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**« 25 » март 2019 ел** **№ 119**

Законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл жирлеге жирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләрнең мониторингын үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл жирлеге жирле үзидарә органнарының законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл жирлеге жирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр мониторингын үткәрү буенча эшчәнлеген камилләштерү максатында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл жирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл жирлеге Советы карар бирә:

1. Карарга теркәлгән "Законнарга һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл жирлеге жирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларына кертелгән үзгәрешләрнең мониторингын үткәрү турында нигезләмәне" расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына:

нормалар иҗат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләргә;

җаваплы итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге
Советы рәисе урынбасары А.Н.Еремин